**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2017 елның 21 апреле №77

Күгәй авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Күгәй авыл җирлеге башлыгы Хисаметдинова Ф.Х. мәгълүматларын тыңлап фикер алышканнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 38 пунктын, 14 статьясындагы 3 өлешен исәпкә алып, Күгәй авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Күгәй авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын танырга:

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябрендәге 140 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында Нигезләмәне раслау хакында"карар;

-- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябрендәге 140 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында»2015 елның 21 июлендәге 186 номерлы;

-- "Күгәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм "Күгәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 2014 елның 5 ноябрендәге 140 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" 2016 елның 15 апрелендәге 37 номерлы (2015 елның 21 июлендәге 186 номерлы Күгәй авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)карары;

2. Бу карарны Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Күгәй авыл җирлегендә түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Күгәй авылы Тынычлык урамы, 22 йорт (җирлек администрациясе бинасы), һәм Зеленодол муниципаль районы мәгълүмат сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталы составында Интернет челтәрендә урнаштырырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru.).

3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль район Советына 2017 елның 24 апреленә кадәр җибәрергә.

**Күгәй авыл җирлеге башлыгы** **Ф. Х. Хисаметдинова**